ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2021 п.г.т.Алексеевское № 387

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 19 июлендәге 193 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 06 сентябрендәге 821 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 19 июлендәге 193 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының (2019 елның 19 ноябрендәге үзгәрешләре белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәгә 3 нче таблицаның 4-7 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «4. | Авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы бистәләрдә урнашкан | педагогик хезмәткәрләр | дүртенче | 5,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | рус теле булмаган белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныфларда рус теле һәм 5-11 сыйныфларда әдәбиятын укыту | вазыйфалары | | |
| | | структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | беренче - икенче | 5,0 |
| 5. | Авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы бистәләрдә урнашкан рус булмаган мәктәпкәчә төркемнәрдә балаларны рус теленә өйрәтү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | өченчесе - дүртенче | 5,0 |
| 6. | Рус телендә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларында туган тел (татар, чуаш, мари һ.б. ны) һәм әдәбият укыту | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | дүртенче | 5,0 |
| | | структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | беренче | 5,0 |
| 7. | Балаларны рус булмаган мәктәпкәчә төркемнәрдә туган телгә (татар, чуваш, мари һ.б., рус теленнән тыш) өйрәтү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | өченчесе - дүртенче | 5,0 |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **А.В.Симашева**